


Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбендә озак еллар уку йортынын директоры, укытучысы, акыллы остазы булган Фаиль Нәим улы Секаев туганнары, кvп санлы укучылары һәм авылдашлары искә алу конемә багышланган тантаналы линейкада катнашкан. Бvген әлеге мәктәп горур анын исемен йортә. Линейкада анын тормыш иптәше Тәнзилә Юсиф кызы Секаева, Фаиль улы Алмаз, Татар Тавла авылы жирлеге башлыгы урынбасары Зульфия Касим кызы Давыдова да катнашканнар.

Мәктәптә урнашкан традиция буенча, бу конне беренче сыйныф укучыларын «Россия боркетләре» балалар оешмасына кабул иткәннәр. Мәктәп директоры Ирфан Касим улы Булатов барлык укучыларга vз Ватанынның намуслы чын патриотлары булырга чакырды. Фаиль улы Алмаз Секаев, Касим кызы Зульфия Давыдова балаларга ин жылы котлаулар һәм теләкләр белән морәжәгать иткәннәр һәм беренче сыйныф укучыларына истәлекле бvләкләр тапшырганнар.

Линейканын икенче олешендә козге татлы ярминкә vткән. Сыйныф житәкчеләре житәкчелегендә укучылар, әти-әниләре ярдәме белән бергә пешергән камыр ризыкларын, бик теләп сатканнар. Тупланган акчага кирәкле медикаментлар сатып алырга һәм СВОда катнашкан сугышчыларга жибәрергә булганнар.